# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

КАРАР

«01» 04 2019 ел Яр Чаллы № 1205/1

«Габдулла Тукайның туган көненә багышланган
район чарасын әзерләү һәм үткәрү турында »

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 24 апрелендә Түбән Суыксу авылы мәдәният йортында Габдулла Тукайның туган көненә багышланган район чарасын оештырырга һәм үткәрергә.
2. Габдулла Тукайның туган көненә багышланган «Тау башына салынгандыр безнең авыл» район рәсем конкурсы турында нигезләмәне расларга (1 кушымта).
3. Тукай муниципаль районының авыл китапханәчеләре өчен Г. Тукай көненә багышланган «Шигърият чишмәсе ул – матурлык» чарасына иң яхшы сценарий район конкурсын уздыру турында нигезләмәне расларга (2 кушымта).
4. Габдулла Тукайның туган көненә багышланган «Елның һәр көне шигырь булырга мөмкин» район шигъри марафонын үткәрү турында нигезләмәне расларга (3 кушымта).
5. Чараның чыгымнар сметасын расларга (4 кушымта).
6. Әлеге карарны муниципаль районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.
7. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Г.Ю. Шакировага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Г. Авзалов

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 1 апрелендәге 1205/1санлы карарына 1 кушымта

| КИЛЕШТЕРЕЛГӘН: | КИЛЕШТЕРЕЛГӘН: | РАСЛАНГАН: |
|---|---|---|
| «Тукай муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» МБУ директоры | Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе |
| __________ Л.И. Йосыфова | __________ Г.Ю. Шакирова | __________ Л.Г. Авзалов |

**Габдулла Тукайның туган көненә багышланган**
**«Тау башына салынгандыр безнең авыл»**
**район рәсем конкурсы турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Тау башына салынгандыр безнең авыл» район конкурсы (алга таба – конкурс) Габдулла Тукайның туган көненә багышланган чаралар кысаларында уздырыла.

## 2. Конкурсны оештыручы

2.1. Конкурсны гамәлгә куючы – «Тукай муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесе.

2.2. Конкурсны оештыручы – «Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» МБУ.

## 3. Балалар иҗаты конкурсының максатлары һәм бурычлары

Конкурсның төп максаты – балаларда рәсем сәнгатенә, татар сәнгать культурасы әсәрләренә кызыксыну уяту, аларны туган як риваятьләре һәм Габдулла Тукай иҗаты белән таныштыру.

Бурычлар:

- балаларда эмоциональ күренешләрне, сәнгать тәмен, иҗади хыялын үстерү;
- балаларда хис-эмоцияләрне белдерүне, сәнгать зәвыгын, иҗади хыялны үстерү;
- аралашу сәләтен һәм күнекмәләрен үстерү, критиканы дөрес кабул итәргә өйрәтү;
- балаларда сәнгатькә тотрыклы кызыксыну уяту;
- туган як иҗатына патриотик мөнәсәбәт тәрбияләү;
- сәнгать иҗаты өлкәсендә талантлы балаларны ачыклау.

## 4. Катнашучыларның категориясе

4.1. Конкурста катнашу өчен мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре, өстәмә белем бирү учреждениеләре укучылары, районның гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары чакырыла.

4.2. Конкурс түбәндәге яшь төркемнәре буенча уздырыла:

1 төркем – 7 яшькә кадәр, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр;

2 төркем – 8 яшьтән 12 яшькә кадәр;

3 төркем – 13 яшьтән 18 яшькә кадәр.

## 5. Конкурсны үткәрү шартлары

5.1. Конкурсның тематикасына һәм максатларына туры килгән рәсемнәр генә конкурста катнаша.

5.2. Конкурс эшләре Г. Тукай әсәрләренә багышланган булырга тиеш.

5.3. Рәсемнең размеры – паспарту белән бергә А3 форматында.

5.4. Башкару техникасы ирекле (карандаш, фломастер, гуашь, акварель, пастель, май, катнаш техника һ.б.).

5.5. Бәяләү критерийлары:

- билгеләнгән темага туры килү;
- эшләнмәләрне башкаруга иҗади якын килү;
- иҗади осталык, иҗади фантазия, башкару сыйфаты;
- башкаруның үзенчәлеге.

5.6. Гаризалар 1 кушымтадагы форма буенча кабул ителә.

5.7. Һәрбер рәсемне имзаларга кирәк. Рәсемнең алгы ягында, уң яктан аскы почмакта күрсәтергә кирәк: исеме «Тау башына салынгандыр безнең авыл», авторның исеме, фамилиясе, атасының исеме тулысынча, яше, авыл җирлеге (2 кушымта).

5.8. Катнашучы тарафыннан тәкъдим ителән эшләр саны чикләнмәгән.

5.9. Конкурста катнашу өчен 50 сум күләмендә оештыру взносы каралган.

5.10. Конкурста катнашу өчен 2019 елның 19 апреленә кадәр гариза тутырырга һәм ilmira.akimova@tatar.ru электрон почтасына (рәсем конкурсы тамгасы белән) яки Яр Чаллы ш., Муса Җәлил пр., 46 йорт, «Тукай муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» МБУ, (222 кабинет) адресы буенча җибәрергә кирәк. Белешмә өчен телефон: (8552) 70-41-80.

5.11. Гариза белән бергә ҮКС кассасы аша түләнгән оештыру взносын түләү турында квитанцияне (яки күчермәсен) бирергә.

5.12. Конкурс эшләрен тәкъдим итү бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның туган көненә багышланган район чаралары кысаларында узачак.

## 6. Конкурска йомгак ясау

6.1. Конкурста җиңүчеләр жюри тарафыннан һәр яшь төркеме буенча билгеләнә, җиңүчеләр дипломнар һәм катнашучы сертификатлары белән бүләкләнә.

6.2. Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның туган көненә багышланган район чарасы кысаларында узачак.

6.3. Конкурс нәтиҗәләре социаль челтәрләрдә урнаштырылачак: vk/kulturatukay «КультУРА начинается с меня!».

6.4. Барлык сораулар буенча 8(8552) 70-41-80 телефоны аша мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

**Конкурсның оештыру комитеты:**

Йосыфова Л.И. – «Тукай муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» МБУ директоры;

Тәхаева Г.С. – «Тукай муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» МБУ методик-библиографик һәм инновацион эшләр бүлеге мөдире;

Ихсанова Л.Р. – китапханә процессларын автоматлаштыру һәм китапханә фондын комплектлау бүлеге мөдире;

Межуева Э.Р. – үзәкләштерелгән китапханәләр системасы редакторы.

Район рәсем конкурсы турында нигезләмәгә 1 кушымта

**«Тау башына салынгандыр безнең авыл»**
**район рәсем конкурсында катнашу өчен гариза**

1. Катнашучының исеме, фамилиясе, атасының исеме ____________________________
   ______________________________________________________________________________
2. Туган елы, тулы яше________________________________________________________
3. Белем бирү учреждениесе, сыйныф ___________________________________________
4. Җитәкченең яки укытучының исеме, фамилиясе, атасының исеме ______________
   ______________________________________________________________________________
5. Адрес (авыл җирлеге, поселок/авыл)_________________________________________
6. Телефон ____________________________________________________________________
7. E-mail _____________________________________________________________________

Дата «___»____________ 20__ ел

Район рәсем конкурсы турында нигезләмәгә 2 кушымта

## Этикетка үрнәге

| | |
|---|---|
| Авторның исеме, фамилиясе, атасының исем | |
| Җитәкченең исеме, фамилиясе, атасының исеме | |
| Туган елы (тулы яше) | |
| Авыл җирлеге, авыл | |

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 1 апрелендәге 1305/1 санлы карарына 2 кушымта

КИЛЕШТЕРЕЛГӘН:
«Тукай муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» МБУ директоры
_____ Л.И. Йосыфова

КИЛЕШТЕРЕЛГӘН:
Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары
_____ Г.Ю. Шакирова

РАСЛАНГАН:
Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе
_____ Л.Г. Авзалов

**Тукай муниципаль районының авыл китапханәчеләре өчен Г. Тукай көненә багышланган «Шигърият чишмәсе ул – матурлык» чарасына иң яхшы сценарийга район конкурсын уздыру турында нигезләмә**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1 Конкурсны гамәлгә куючы – «Тукай муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесе.

1.2 Конкурс Габдулла Тукайның туган көнен бәйрәм итү кысаларында үткәрелә.

1.3 Чарага иң яхшы сценарий район конкурсы Тукай муниципаль районының авыл китапханәчеләре өчен уздырыла.

1.4 Әлеге нигезләмә конкурс уздыруның максатын, бурычларын, шартларын һәм срокларын билгели.

**2. Конкурс уздыруның максатлары һәм бурычлары**

2.1 Мәктәпкәчә яшьтәге балалар һәм мәктәп балалары белән эшләүнең яңа формаларын һәм нәтиҗәле ысулларын гамәлгә кертү.

2.2 Китапханә белгечләренең иҗади потенциалын стимуллаштыру, һөнәри компетенция дәрәҗәсен күтәрү.

2.3 Тукай муниципаль районының югары һөнәри осталыкка ия, талантлы китапханәчеләрен ачыклау һәм кызыксындыру.

**3. Конкурс үткәрү этаплары**

3.1 Конкурс өч этапта үткәрелә:

- I этап (01.04.2019 – 05.04.2019) – авыл китапханәләрендә чараларны карау.

- II этап (12.04.2019) – жюри чараның иң яхшы сценариен билгели.

- III этап - Габдулла Тукайның туган көненә багышланган район чарасы кысаларында җиңүчеләрне бүләкләү.

## 4. Эшләрне рәсмиләштерүгә таләпләр

4.1 Чараның сценариесе түбәндәге формада булырга мөмкин: бәйрәм, китапханә дәресе, иртәлек, квест, презентация, виртуаль күзәтү яки күргәзмә һ.б.

4.2 Материаллар конкурсның оештыру комитетына җибәрелә.

4.3 Текст эше түбәндәге редакторда башкарылырга тиеш: Microsoft Word, шрифт Times New Roman, 14 кегль. Эш күләме 5 биттән артмаска тиеш.

4.4 Чараның мәҗбүри шарты – чарада катнашучылар арасында флэшмоб үткәрелергә тиеш: Габдулла Тукайның «Китап» шигырен уку (кушымта).

4.6 Конкурска сценарийлар электрон рәвештә түбәндәге адрес буенча кабул ителә: ilmira.akimova@tatar.ru.

## 5. Эшләрне бәяләү

5.1 Эшләрне бәяләү билгеләмәләре:

Иҗат эше эчтәлегенң конкурс темасына туры килүе – 0 дән 5 баллга кадәр;

Теманы тулысынча һәм тирән ачу – 0 дән 5 баллга кадәр;

Идеянең үзенчәлекле булуы, новаторлык – 0 дән 5 баллга кадәр;

Киләчәктә гамәлгә кертү мөмкинлекләре – 0 дән 5 баллга кадәр;

5.2 Эш өчен бәя һәр критерий буенча алынган баллар суммасы буларак билгеләнә.

## 6. Оештыру комитеты

6.1 Конкурсның оештыру комитеты алынган конкурс эшләрен терки, конкурсның барлык формаль шартлары үтәлешен тикшерә.

## 7. Жюри

7.1 Жюри «Тукай муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» МБУ белгечләреннән тора.

7.2 Жюри иң яхшы конкурс эшләрен сайлап ала.

## 9. Җиңүчеләрне бүләкләү

9.1 Җиңүчеләргә дипломнар һәм истәлекле бүләкләр тапшырыла.

Тукай муниципаль районының авыл китапханәчеләре өчен Г. Тукай көненә багышланган «Шигърият чишмәсе ул – матурлык» чарасына иң яхшы сценарий район конкурсын уздыру турында нигезләмәгә кушымта

Китап
(Аз гынасы русчадан)

Һич тә күңлем ачылмаслык эчем пошса,
Үз-үземне күрәлмичә, рухым төшсә,
Җәфа чиксәм, йөдәп бетсәм, бу башымны
Куялмыйча жанга җылы һичбер төшкә;

Хәсрәт соңра хәсрәт килеп алмаш-алмаш,
Күңелсез уй белән тәмам әйләнсә баш,
Күзләремдә кибеп тә җитмәгән булса
Хәзер генә сыгълып-сыгълып елаган яшь, —

Шул вакытта мин кулыма китап алам,
Аның изге сәхифәләрен актарам;
Рәхәтләнеп китә шунда җаным, тәнем,
Шуннан гына дәртләремә дәрман табам;

Укып барган һәрбер юлым, һәрбер сүзем
Була минем юл күрсәткүче йолдызым;
Сөйми  башлыйм бу дөньяның ваклыкларын,
Ачыладыр, нурланадыр күңлем, күзем;

Җиңелләнәм, мәгъсумләнәм мин шул чакта,
Рәхмәт әйтәм укыганым шул китапка;
Ышанычым арта минем үз-үземә,
Өмид берлән карый башлыйм булачакка.

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 1 апрелендәге 1205/1 санлы карарына 3 кушымта

| КИЛЕШТЕРЕЛГӘН: | КИЛЕШТЕРЕЛГӘН: | РАСЛАНГАН: |
|---|---|---|
| «Тукай муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» МБУ директоры | Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе |
| ____________ Л.И. Йосыфова | ____________ Г.Ю. Шакирова | ____________ Л.Г. Авзалов |

"Централизованная библиотечная система Тукаевского муниципального района"

**Габдулла Тукайның туган көненә багышланган**
**«Елның һәр көне шигырь булырга мөмкин»**
**район шигъри марафонын үткәрү турында нигезләмә**

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Габдулла Тукайның туган көненә багышланган «Елның һәр көне шигырь булырга мөмкин» район шигъри марафоны (алга таба – марафон) Габдулла Тукайның туган көненә багышланган чаралар кысаларында уздырыла.

1.2. Марафонны оештыручы – «Тукай муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесе.

1.3. Марафонның партнёры: Факил Сафин – ТР Язучылар берлегенең Яр Чаллы бүлекчәсе җитәкчесе.

1.4. Марафонның максатлары:

- җәмгыятьнең әдәби-тел культурасын үстерү;
- гражданнарны Ватанга һәм туган телгә карата уңай караш һәм мәхәббәт тәрбияләү өчен иҗади эшкә тарту;
- Г. Тукай тормышы һәм иҗаты мисалында балалар һәм яшьләрдә патриотизм һәм милли үзаң тәрбияләү.

1.5. Марафонның бурычлары:

- укучыларны татар шигърияте дөньясына, милли мәдәният кыйммәтләренә җәлеп итү;
- Татарстан һәм башка илләрнең әдәби мирасын өйрәнү нигезендә балалар һәм яшүсмерләрнең иҗади сәләтләрен үстерү;
- катнашучыларны марафон барышында иҗади эшкә тарту.

### 2. Марафонның темасы һәм чыгыш яауга таләпләр

2.1. Марафонның темасы: «Елның һәр көне шигырь булырга мөмкин».

2.2. Марафонда катнашучылар темага туры китереп, татар шагыйренең рус яки татар телендә берәр әсәрен яисә шагыйрь турында әсәр тәкъдим итәләр.

2.3. Чыгыш 5 минуттан артмаска тиеш. Музыкаль бизәлеш хуплана.

2.4. Башкару осталыгын бәяләү билгеләмәләре:

- башкару осталыгы дәрәҗәсе һәм техникасы (дикция, сөйләм техникасы, тавыш белән идарә итү);

- артистлык һәм сәхнә культурасы;
- башкарган әсәрнең идея-тематик ниятен, авторлык идеяләрен аңлау һәм ачу;
- марафонның билгеләнгән тематикасына туры килү.

### 3. Конкурс үткәрү тәртибе һәм катнашу шартлары

3.1. Марафонда районның гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары түбәндәге яшь категорияләре буенча катнаша:

- 1 төркем: 4-6 яшь;
- 2 төркем: 7-11 яшь;
- 3 төркем: 12-14 яшь;
- 4 төркем: 15-18 яшь;
- 5 төркем: 19 яшь һәм аннан өлкәнрәк.

3.2. Конкурс 2019 елның 25 мартыннан 19 апреленә кадәр «Тукай муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесендә үткәрелә (Яр Чаллы ш., Муса Җәлил пр., 46 йорт).

3.3. Марафонда катнашу өчен видеоролик әзерләргә һәм социаль челтәрләрдә үз битендә һәм vk/kulturatukay «КультУРА начинается с меня!» битендә #Марафонтукая2019 һәм #Тукаевскийрайон хэштегы белән урнаштырырга кирәк.

3.4. Һәр катнашучы марафонда бер генә ролик тәкъдим итә ала.

3.6. Гаризалар кушымтадагы форма буенча кабул ителә.

3.7. Конкурста катнашу өчен 2019 елның 19 апреленә кадәр гариза тутырырга һәм ilmira.akimova@tatar.ru электрон почтасына («Елның һәр көне шигырь булырга мөмкин» тамгасы белән) яки Яр Чаллы ш., Муса Җәлил пр., 46 йорт, «Тукай муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» МБУ, (222 кабинет) адресы буенча җибәрергә кирәк. Белешмә өчен телефон: (8552) 70-41-80. Гаризаларны видеороликка сылтама белән җибәрергә кирәк. Сылтама эшләмәсә, гариза кабул ителми.

3.8. Видеороликка таләпләр:

- видеороликның дәвамлылыгы 5 минуттан артмаска тиеш;

- укый башлар алдыннан түбәндәге мәгълүмат яңгырарга тиеш: исем, фамилия. Яшәү урыны (авыл җирлеге). Мин «Елның һәр көне шигырь булырга мөмкин» шигъри марафонында катнашам. Шигырьнең исеме. Автор;

- шигырьләр яттан сәнгатьле башкарылырга тиеш, видеороликта музыкаль бизәлеш һәм театральләштерү элементлары булырга мөмкин, ләкин төп рольне шигырь сөйләү осталыгы били осталыгы уйнарга тиеш;

- кадрда (чыгыш ясаучы кулында, китап киштәсендә һ.б.) Тукай шигырьләре җыентыгының булуы мәҗбүри шарт булып тора;

- марафонда катнашу өчен тәкъдим ителгән видеоролик яхшы сыйфатта булырга тиеш, профессиональ төшерү хуплана, ләкин мәҗбүри түгел.

## 4. Конкурска йомгак ясау

4.1. Марафонга йомгак оештыру комитеты тарафыннан һәр яшь төркеме буенча марафон үткәрү кысаларында ясала. Җиңүчеләр дипломнар һәм катнашучы сертификатлары белән бүләкләнә.

4.2. Марафонда җиңүчеләрне бүләкләү бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның туган көненә багышланган район чарасы кысаларында узачак.

4.3. Кокурс нәтиҗәләре социаль челтәрләрдә урнаштырылачак: vk/kulturatukay «КультУРА начинается с меня!».

4.4. Йомгак ясаганнан соң, җиңүчеләрнең марафонны оештыручылар белән элемтәгә керүен сорыйбыз.

Барлык сораулар буенча 8(8552) 70-41-80 телефоны аша мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

**Конкурсның оештыру комитеты:**

1.Сафин Ф. М.: ТР Язучылар берлегенең Яр Чаллы бүлекчәсе җитәкчесе. Татарстан Республикасының атказанган мәдәният эшлеклесе ;

2. Якупова С.М.: Шагыйрә. Сажидә Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты;

3. Ситдыйкова А.М.: Шагыйрә. Сажидә Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты.

Район нәфис сүз осталары турында нигезләмәгә кушымта

**«Елның һәр көне шигырь булырга мөмкин» район шигъри марафонында катнашу өчен гариза**

1. Катнашучының исеме, фамилиясе, атасының исеме______________________
2. Туган елы, тулы яше____________________________________________
3. Белем бирү учреждениесе, сыйныф_________________________________
4. Әсәрнең исеме ________________________________________________
5. Җитәкченең яки укытучының исеме, фамилиясе, атасының исеме_________
   ______________________
6. Адрес (авыл җирлеге, поселок/авыл)_____________________________________
7. Телефон _______________________________________________________
8. E-mail ________________________________________________________
9. Видеороликка сылтама ______________________________________________

Тукай муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 1 апрелендәге 12 05/1
санлы карарына 4 кушымта

**Г.Тукайның туган көненә багышланган район чарасын үткәрү буенча чыгымнар сметасы**

| № | Товар исеме | Саны | Берәмлек | Бәясе | Суммасы, сумнарда | Финанслау чыганаклары |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Сувенир продукциясе | 50 | данә | 300,00 | 15000,00 | «Тукай муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» МБУ |
| 2 | Китаплар | 50 | данә | 150,00 | 7500,00 | «Тукай муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» МБУ |
| 3 | Фирма билгесе белән пакетлар | 100 | данә | 30,00 | 3000,00 | «Тукай муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» МБУ |
| 4 | Диплом өчен рамкалар | 50 | данә | 100,00 | 5000,00 | «Тукай муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» МБУ |
| 5 | Мәгълүмати стенд | 2 | данә | 15000,00 | 30000,00 | «Тукай муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» МБУ |
| 6 | Чәчәкләр | 5 | данә | 500,00 | 2500,00 | «Тукай муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» МБУ |
| **ИТОГО:** | | | | | **63000,00** | |

Барлыгы: 63000,00 (алтыш өч мең сум 00 тиен)

Тукай муниципаль районы
үзәкләштерелгән китапханәләр
системасы» МБУ директоры Л.И. Йосыпова

Баш бухгалтер С.Г. Чернова